## Иҗади ай

**/Безнең уңышлар/**



Март ае район күләмендә уздырылган төрле иҗади чараларга һәм конкурсларга бик бай булды. Безнең мәктәп тә бу чараларда бик актив катнашты. Иҗади ай бакча яшендәге балалар арасында 3нче мартта уздырылган **“Татар малае, Татар кызы - 2021”** конкурсы белән башланып китте. Бу бәйгедә безнең бакча төркемендә тәрбияләнүче **Сафиуллина Гөлсем**, бик оста чыгыш ясап, җиңүче исемен алды. Шул ук көнне, узган айда уздырылган **“Театрның тылсымлы сәхнәсе”** конкурсы нәтиҗәләре чыгарылып, безнең бакча төркеме I урынга ия булды. (Җитәкчеләре **Гөлүсә Насыйрова** һәм **Альмира Бәширова**).

4нче мартта **«Живая классика»** дигән Бөтенроссия конкурсының район этабы уздырылды. Бу бәйгедә безнең мәктәптән катнашкан **Насыйрова Сара** – I урынны алды. **Хәйруллин Айназ** белән **Нукина Виктория** лауреат исеменә лаек булдылар. (Җитәкчеләре **Раушания Назмутдинова** һәм **Гөлнур Кадыйрова**).

Узган еллардагы кебек үк, быел да безнең мәктәп укучылары район буенча уздырыла торган иҗат отчет чарасында актив катнашты. 9-нчы март көнне авыл мәдәният йортында куелган тамаша халык тарафыннан да, районнан килгән комиссия тарафыннан да бик югары бәяләнде.



10-нчы март безнең мәктәпнең башлангыч сыйныф укучыларыннан оештырылган **“Яшь буыннар” коллективы** көнне район үзәгендә балаларның **“Без бергә”** халык иҗаты фестивалендә катнашты. “Аулак өй” тамашасы өчен безнең мәктәп III урынга, ә күргәзмә композициясе буенча I урынга лаек булды. Моңа кадәр “Туган телем – серле телем” район конкурсында **“Халкыбызның күңел җәүһәрләре”** номинациясендә безнекеләр I урынны алган иделәр. Бу эшләрне оештыруда һәм балаларны әзерләүдә “Оста куллар” түгәрәген һәм мәктәпнең тәрбия эшләрен җитәкләүче **Рузилә апа Хәйруллина** зур тырышлык куйды.

16нчы мартта район үзәгендә “Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын” дигән **XI Халыкара нәфис сүз бәйгесенең** муниципаль туры булып узды. Безнең мәктәптән конкурста **Сара Насыйрова** катнашып, Марсель Галиевның “Рух” китабыннан “Туган тел сихәте” поэмасы белән чыгыш ясады. Нәтиҗәләр буенча, Сара I урыны яулап, Казанда уздырылачак республика турында катнашу мөмкинлеге алды. (Җитәкчесе **Фәнүзә апа Гафиятуллина**).

***Рубриканы Сара Насыйрова әзерләде***

## Уңышлы ярыш

**/Безнең спорт/**



Язгы каникулның ахырында, 29нчы март көнне Аксубай район үзәгендә милли көрәш буенча Аксубай, Норлат һәм Чистай районнары арасында турнир үткәрелде. Ярышка һәр катнашучы районнан 30дан артык көрәшчеләрдән торган командалар катнашты. Безнең мәктәптән көрәш түгәрәгенә йөрүче малайларның күбесе катнашып, зур уңышка ирешеп кайттык. Ярышның гомуми нәтиҗәләре түбәндәгечә:

- 25 кг авырлыкта – **Сәгъдиев Рәмзис** – I урын, **Җамалетдинов Зөлфәт** белән **Донсков Артур** – III урыннар;
- 30 кг авырлыкта – **Хәбибрахманов Абдулла** – II урын;
- 45 кг авырлыкта – **Галимов Рияз** – I урын, **Хәйруллин Айназ** – III урын;
- 50 кг авырлыкта – **Галимов Рияз** – III урын;
- 55 кг авырлыкта – **Нурматов Халит** белән **Камалов Илдус** – I урыннар, **Хәбибрахманов Ильяс** – II урын;
- 60 кг авырлыкта – **Камалов Илдус** – I урын, **Нурматов Халит** – II урын;
- 60 кг авырлыкта – **Гогиев Аслан** – III урын.

Моңа кадәр бер ярыштан берьюлы шундый күп урыннар алганыбыз юк иде әле. Безне өйрәтеп, ярышларга йөртүче тренерыбыз **Камалов Илһам абыйга** сәламәтлек, зур ихтыяр көче телибез.

***Рубриканы X сыйныф укучысы Халит Нурматов әзерләде***

**/Котлыйбыз!/**

Март аенда дөньяга килгән хөрмәтле укытучыбыз **Гафиятуллина Фәнүзә апаны**, бакчага йөрүче **Хәбибрахманова Асияне**, укучылардан **Морадимов Илсур** белән **Сафиуллина Зөлфирәне** туган көннәре белән котлыйбыз. Укулары һәм хезмәтләрендә уңышлар, ныклы сәламәтлек телибез. Барча теләкләрегез дә тормышка ашсын.


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова, Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова, Зөлфирә Сафиуллина



# Мәктәп хәбәрчесе

**№3** (№24) март 2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


**Гәзитнең бу санын X сыйныф укучылары әзерләде**

**/Мөхәррир сүзе/**

## Саклanганнар сакланыр

Мәктәпләрдә иң озын чирек ахырына якынлашты. 22-нче марттан укучылар язгы каникулга чыкты. Ул 31-нче мартка кадәр дәвам итәчәк.

Уку елының өченче чиреге һәрвакытта да укучыларны нык ялыктыра. Бу чирекнең озын булуы белән бергә, төрле олимпиадалар, тест тикшерүләре, фәннәрнең иң катлаулы бүлекләрен өйрәнүләрнең шушы чиреккә туры килүе балалар өчен өстәмә авырлыклар тудыра. Моңа тагын кыш айларында витаминлы тукланунның кимүе дә, яшь организмга тискәре йогынты ясый.

Каникул көннәрендә ата-аналар балаларының саф һавада күбрәк булуына игътибар итсен иде. Ачык һавада физик хезмәт тә файдага гына. Бу вакытта компьютер, телевизорлар хуҗаларыннан “котылып” торачак. Күтәренке кәеф булдыру өчен беркайчан да юмор хисен онытмагыз. Уен-көлке – үзе бер ял, ди белгечләр. Балаларга бу чорда файдалы һәм кызыклы яллар, ә иң мөһиме – шәхес буларак үсешен тәэмин итәрлек шартлар тудыру зарур.



Балаларның ялын оештырганда тормыш иминлеген һәм куркынычсыз-лыкны тәэмин итүгә аерым игътибар бирелсен иде. Укучыларга каникул-ларга таралыр алдыннан түбәндә китереләчәк кагыйдәләр аңлатып үтелә:

- юлда йөрү һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре;
- җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту һәм өйдә үзең генә калу кагыйдәләре;
- тайгак урыннарда егылудан саклану;
- кичке сәгать сигездән соң өлкәннәрдән башка урамга чыкмау;
- түбәләрдән кар яки боз төшүдән саклану;
- елгада боз ватылып, янсә туңмаган урыннырда батудан саклану:
- яр буйларында тирән карга батудан, янсә кар ишелеп аста калудан саклану;
- телефон һәм компьютердан файдалану кагыйдәләре.

Югарыда санап кителгән кагыйдәләрне үтәү укучыларыбызның иминлеге һәм сәламәтлеген саклау өчен мөһим. Безнең зур елга буенда яшәвебез дә олыларның кечкенәләргә карата игътибарлырак булуын сорый. Гомумән, һәркем үз сәламәтлеген үзе кайгыртып, тиешле чараларны үтәгәндә генә иминлеккә ирешеп була. Каникулдан балалар ял итеп, сәламәтлекләрен ныгытып, укуга көч туплап килсеннәр.

***Фәнүзә Гафиятуллина, X-XI сыйныфлар җитәкчесе***

## 8 март – Халыкара хатын-кызлар көне белән!




Язгы кояш нуры җир йөзен март аенда җылытса, яраткан әни-әбиләребез, апа-сеңелләребез һәрвакытта да! Яз башында килгән бу бәйрәм табигатьнең җанлана башлаган вакытына туры килүе дә, хатын-кыз табигатенә тиңдәш. Газиз әниләребез, әбиләребез, апа-сеңелләребез, сабакташ кызларыбыз! Сезне бу бәйрәмдә тагын да күркәмрәк һәм гүзәлрәк булуыгызны телибез. Йөзегездән елмаю, күңелләрегездән йомшаклык, сабырлык беркайчан да китмәсен. Сезне яклаучы-саклаучы ир-егетләрегез, улларыгыз шатлык кына китерсен.

***10-11-нче сыйныф егетләре***



## 3-нче чирек нәтиҗәләре

**/Рәсми хәбәрләр/**

20-нче март көнне уку елының иң озын 3 нче чиреге тәгәлләнде. Мәктәптәге 53 укучының 42 сенә чирек билгеләре чыгарылды. Узган чиреклрдәге кебек үк, мәктәп күләмендә барлыгы ике отличник – 3 нче сыйныф укучысы Закирова Ләйсән һәм 4нче сыйныфтан Гафиятуллин Фаил. 17 укучы "4"ле, "5"ле билгеләренә генә өлгерде. Шулай итеп, нәтиҗәләр буенча белем сыйфаты 45,2% тәшкил итә. Бу күрсәткеч узган чирек белән чагыштырганда 12%ка түбән.

Узган чиректә 9нчы сыйныф укучыларының рус теленнән йомгаклау әңгәмәсе узды. Нәтиҗәләр буенча алар уртача 16,1 бал җыйды, барысы да бу имтиханны уңышлы үтте. Шулай ук бу чиректә чыгарылыш сыйныфлар өчен сынау имтиханнары да уздырылды. Чирек ахырында һәр предметтан административ контроль эшләр дә үткәрелде.

***Илдар Хәбибуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***

**/Безнең бәйрәмнәр/**




## Ягез әле, кызлар!

Җылы кояш нурларына төренеп, җитез гөрләвекләре белән йөгереп, язның беренче ае — март та килеп җитте. Барыбызга да билгеле язның иң беренче бәйрәме — 8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне. Барлык әбиләр, әниләр, апалар һәм кызларны язгы чәчәкләр кебек ярату һәм хөрмәтләү бәйрәме.

Безнең мәктәп укучылары да бу тантаналы көндә игътибарсыз калмадылар, әлбәттә. 5 нче март көнне 4 дәрестән соң барыбыз да спорт залына җыелдык. Укучы кызларыбыз, уңганлык һәм тырышлыкларын күрсәтү өчен, командаларга бүлеп, кызыклы ярыш уздырдылар. Беренче команда үзенә **"Яз кызлары"** , ә икенчесе **,,Ландышлар"** атамасын сайладылар. Ярыш бик киеренке үтте, һәрбер як үзләрен төрле эшләрдә уңганлык һәм тырышлыкларын, һәм шул ук вакытта нәзәкатьле, хисчән булуларын күрсәттеләр. Тик һәрбер ярышта да нинди дер команда җиңүче титулын алырга тиеш инде. Бу бәйгедә ,,Ландышлар" командасы өстенлеккә чыкты. Тик бу "Яз кызларының" җиңелүен түгел, ә икенче урын алуларын гына күрсәтә. Мин үзем ,, Ландышлар" командасыннан булып, кайбер вакытларда көндәшләремә сокланып карап тордым, һәм ахырга кадәр җиңү аларныкы булыр дип уйлаган идем.

***Сара Насыйрова, Х сыйныф укучысы***

## Нәүрүз мөбарәк булсын!



Нәүрүз – төрки халыкларның кышны озату, язны каршылау бәйрәме. Ул бик борынгы заманнардан ук, язгы көн белән төн тигезләшкән көннәрдә үткәрелгән. Бу көннәр мәктәп календаре буенча 3 нче чирек тәгәлләнеп, язгы каникуллар башланган вакытка туры килә. Безнең мәктәптә кабул ителгән гадәт буенча, һәр уку чиреге нинди дә булса бәйрәм белән тәгәлләнә. Нәүрүз бәйрәме бездә 1996 нчы елдан бирле уздырылып килә. Аның аерылгысыз өлешләре – авыл буйлап бизәлгән атларда йөрү, самоварда кайнаган чәй һәм коймак белән сыйлану, сыерчык оялары күргәзмәсе, һәм мәктәп ярминкәсе.

Ачык һавада үткәрелә торган бәйрәмдә Майна авылы халкы, һәм башка авыллардан килеп укучыларның әти-әниләре дә катнаша. 20нче март көнне иртәдән үк мәктәп алдында атлар бизәлде. Кыңгыраулы, бизәлгән атларда балалар авыл буйлап җырлый-җырлый урам әйләнделәр. Математика укытучысы Фәнил абый гармунда уйнап барды. Атлар әйләнеп килгәч, укучылар Кыш бабайны озатып, Нәүрүзбикәне каршылау өчен чыгышларын куйдылар.



Һава торышы салкынча һәм җиллерәк булса да, барыбызның да кәефләр күтәренке иде. Бәйрәмдә катнашучылар һәм кунакларны пешекче апаларыбыз самовар чәе һәм коймактан авыз иттерделәр.

Бәйрәм тамашасы тәгәлләнгәч, түргә сыерчык оялары ясап килгән укучылар чыкты. Быел яз бәйрәменә барлыгы 13 сыерчык оясы ясалган иде. Мәктәп директоры оя ясаган һәр укучыга бүләкләр тапшырды. Әлбәттә инде, Нәүрүз бәйрәменең кульминациясе – ярминкә. Укучылар үзләре әзерләп килгән товарларын саттылар. Товарларның күпчелеге өйдә пешергән ризыклардан гыйбарәт иде. Шулай ук, кул эшләнмәләре белән сыерчык оялары да сатылды. Бу Нәүрүз ярминкәсендә катнашкан укучылар барлыгыы 12 мең сумнан артык табыш алдылар.

***Рузилә Мөхәммәтова, Х сыйныф укучысы***

**/Укучылар иҗаты/**

### Тамчылар

Тирәмдәге үзгәрешне,
Сөйлим әле, дусларым.
Иртән торган җиремә
Кояш кергән өемә.

Күзен кысып елмаеп
Гөл арасына чумган.
Чакырмаган килеш тә
Түремдә сузылып яткан.

Урамга чакырган була,
Иркәләп нуры белән.
Түбәдән карны төртә
Җылы уклары белән.

Аннан инде тамчылар
Берсен-берсе куыша.
Өшеп арыган алар,
Шуңа сөенә кояшка.

Тамчыдан күл җыела
Шулай көче оеша.
Шатланып очрашуга
Кар ашыйлар кояшта.

Көчләр туплап бергәләп
Гөрләвекләп агалар.
Ашкынышып, куышып
Елгаларга тулалар...

***Рузилә Мөхәммәтова***

## "Каенлык" атамасы

**/Чал тарихта эзле без!/**



Авыл җирләре гадәттә төрле җир-су атамаларына бай була. Аларның кайсылары мәгънәләре белән хәзерге чордагы әйләнә-тирә шартларына туры килсә, кайберләре исә элеккеге заманнардагы чынбарлыкны гына чагылдыра. Түбән Майна җирләрендә менә шундый исеме җисеменә туры килмәгән **"Каенлык"** дип йөртелүче урын бар. Арттагы күлдән китеп, авылдан көнчыгыш яктагы җирләр шулай атала. Шул яктан килеп, авылны урталай бүлгән, язгы сулар Чирмешәнгә агып төшә торган ерганак та халык телендә **"Каенлык елгасы"** дип йөртелә.

Халык риваятьләреннән һәм борынгы карталардан күренгәнчә, чыннан да элек ул якта каеннар үсә торган урман булган. XVIII гасыр ахырында Каенлык урманы хәзерге ындыр яныннан башланып, авыл тирәли әйләнеп һәм Чирмешән буйлап китеп, Иске Әдәм авылы җирләренә кадәр таралып үсеп утырган. Аннан ары китеп, Әдәмсуы елгасының ике яры буйлап Иске Әдәм авылына кадәр килеп терәлгән һәм Чирмешәннең сул яры буйлап Чуаш Ялтаны авылына хәтле сузылган. Иске Әдәм белән ике арадагы юл шул урман буйлап үткән. Ул заманда безнең авыл урнашкан урын Чирмешән буендагы, Шалканаттагы куаклыклар һәм Каенлык урманы эчендәге аланны хәтерләткән. Бары тик Зур чирәм турысы гына ачыклык булып торган. Хәзер элеккеге Каенлыктан Иске Әдәм авылы җирләрендәге **Болгар** куаклыгы гына калган.

Каенлыкны, Имәнлек һәм Югары кырдагы урманнар кебек үк, әле XIX гасырның икенче яртысында ук, чәчүлек мәйданнарын арттыру өчен кисеп бетергәннәр. Ләкин бу урман урыннарындагы җирләр баткаклык һәм комлык булу сәбәпле сөрү өчен уңайсыз. Шунлыктан хәзерге вакытта Каенлык та Имәнлекнең зур өлеше дә күпьеллык үлән үстерү өчен файдаланыла, ә кайбер сазлыклырак җирләрен таллар басып киткән.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

Безнең газеткә Казан шәһәрендәге 2-нче татар гимназиясенең 4-нче сыйныфында укучы Нурия Батыршина үзе язган шигырен җибәрде. Нурия авылга кунакка кайткан чакларында безнең мәктәпкә еш килеп йөри. Узган көз ул безнең бакча балаларына курайда уйнап, мастер-класс күрсәткән иде. Авыл кызлары арасында аның дуслары да күп.

### Яз җитте

Менә яз да җитте,
Кыш үтте дә китте.
Кошлар сайрый һәр көн,
Агачлар яшәрде.

Кояш тора көлеп,
Безне тышка дәшеп.
Әйдә, чыгыйк тизрәк,
Уйнарбыз бергәләп.

***Нурия Батыршина***

**/Безнең очрашулар/**

## ЮХИДИ вәкилләре бездә кунакта




Быел ЮХИДИ хезмәте оешканга 85 ел тулу уңаеннан төрле чаралар уздырыла. Безнең мәктәптә Гафиятуллина Руфия апа җитәкләгән ЮИД төркеме уңышлы эшләп килә. 6 нчы март көнне ЮИД көне хөрмәтенә мәктәп буенча уздырылган рәсем конкурсына нәтиҗә ясалды. Руфия апа конкурста катнашкан барча укучыларга бүләкләр тапшырды.

17нче март көнне безнең яшь инспекторлар агитбригадасының әзерлегән каарга ТР ЮХИДИ идарәсенең Норлат шәһәре бүлегеннән ОПТУ башлыгы Гөлфия апа Гиматдинова һәм Аксубай бүлекчәсеннән Татьяна апа Мартыновалар килде. Укучылар аларга ачык чара күрсәттеләр, юл хәрәкәтләре иминлеге буенча викторина сорауларына җавап бирделәр. Килгән кунаклар чарадан, балалар белән җылы аралашудан канәгать булып киттеләр.

***Халит Нурматов, Х нчы сыйныф укучысы***